Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеевск муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

15.12.2023 Менделеевск ш. № 756

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы 7 нче катнаш төрдәге «Алтын балык» балалар бакчасы Мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлеген вакытлыча туктатып тору турында

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының 7 нче катнаш төрдәге «Алтын балык» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесендә тәрбияләнүчеләрнең тормыш иминлеген тәэмин итү максатыннан, капиталь ремонт ясалуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының башкарма комитеты,

КАРАР БИРӘ:

1. 7 нче катнаш төрдәге «Алтын балык» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе эшчәнлеген вакытлыча туктатып торырга.
2. Менделеевск муниципаль районының мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениеләренә вакытлыча күчереләә торган балалар исемлеген кушымта нигезендә расларга.
3. Ремонт эшләре чорында 7 нче катнаш төрдәге «Алтын балык» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенә йөрми торган тәрбияләнүчеләрдән ата-аналар түләвен алмаска
4. 7 нче катнаш төрдәге «Алтын балык» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе мөдиренә (Е.А.Грицук) учреждение эшчәнлеген туктатып торган вакытка, ремонт эшләрен башкаручы подрядчы оешма белән килешү төзергә, мөлкәтнең сакланышын, телефон элемтәләрен, янгын сигнализациясен тәэмин итәргә.
5. 7 нче катнаш төрдәге «Алтын балык» балалар бакчасы» мәктәпкәчә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләрен, хезмәт хакын саклап, санитария-гигиена эшләренә тартырга
6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.Ш.Ханзаровка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р.Искәндәров